**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

**2025 елның 18 сентябрендәге 2951 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 25 июнендәге 1916 номерлы**
**«“Диалоглар” архитектура-шәһәр төзелеше конференциясен**
**уздыру турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Диалоглар» архитектура-шәһәр төзелеше конференциясен оештыру һәм уздыру сыйфатын яхшырту максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 25 июнендәге 1916 номерлы «“Диалоглар” архитектура-шәһәр төзелеше конференциясен уздыру турында»гы карарына, кушымтасының III һәм IV бүлекләрен түбәндәге редакциядә биреп, үзгәрешләр кертергә:

**«III. Конференцияне уздыру тәртибе һәм шартлары**

3.1. Конференция 2025 елның 4 декабреннән алып 6 декабренә кадәр уздырыла.

3.2. Конференция уздыру адресы Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) 2025 елның 21 ноябреннән дә соңга калмыйча урнаштырылачак.

3.3. Конференциядә катнашучы затлар түбәндәге категорияләргә бүленәләр:

- конференциядә катнашучылар (спикерлар);
- конференция кунаклары, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары.

3.4. Конференциядә катнашучылар (спикерлар) Конференция программасы нигезендә фикер алыша торган мәсьәлә буенча чыгышлар, докладлар һәм презентацияләр рәвешендә мәгълүмат тапшыралар.

**IV. Конференция программасы**

2025 елның 4 декабре:

10.00. Конференция уздыру мәйданчыгын ачу.

10.30 – 17.00. «Яшьләрне һәм креатив индустрияләрне үстерү өчен киңлекләр» темасына чыгышлар, презентацияләр.

2025 елның 5 декабре:

10.30 – 13.50. «Яшьләрне һәм креатив индустрияләрне үстерү өчен киңлекләр» темасына чыгышлар, презентацияләр.

14.00 – 17.30. «Архитектурада һәм шәһәр төзелешендә инновацион стартаплар: идеядән гамәлгә ашыруга» темасына чыгышлар, презентацияләр.

2025 елның 6 декабре:

10.00 – 13.50. «Шәһәр мохите киләчәге: альтернатив торак һәм креатив индустрияләр» темасына чыгышлар, презентацияләр.

14.00 – 17.30. «Шәһәр киңлекләре икътисады» темасына чыгышлар, презентацияләр.».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе башлыгы А.Н. Лобовка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**